ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Ленина, дом 63,
село Старое Шаймурзино, 422460

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ
ШӘЙМОРЗА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин урамы, 63 нче йорт,
Иске Шәйморза авылы, 422460

Тел.: (84375) 3-44-72, 3-43-47, 3-44-44, факс: (84375) 3-44-72,
e-mail: **Sshm.Drz@tatar.ru**, www.sshm-drogganoye.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 апрель 2019 ел № 121

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 2006 елның 2 маендагы 59 – ФЗ номерлы федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Башкарма комитетында (яңа редакциядә) гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» 2019 елның 1 февралендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 4 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.»;

**2)** Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Регламентында:

**6.1 пунктта:**

6.1 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 4 бүлегендәге очраклардан тыш, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап алырга, ә әлеге Регламентның 4.1 пунктындагы 8 пунктчасында каралган очракта, аны бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итү нигезендә, дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәрнамә алырга;»;

сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

7.5.6 пунктында "миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, контроль, күзәтчелек һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыра торган башкарма хакимият федераль органының территориаль органы" сүзләрен «Эчке

эшләр өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органы»сүзләренә алмаштырырга

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы: И.С.Бикчуров